| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

12 сентябрь 2014 ел    Казан шәһәре    № 7-18/т

***"Казан шәһәренең җәмәгать транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында" 31.01.2014 № 7-1/т Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карарына үзгәртүләр кертү турында***

"Бәяләрне (тарифлар) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында" 7 март, 1995 ел, №239 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, 15 июнь, 2010 ел, №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты "Татарстан Республикасы тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре" карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. "Казан шәһәренең җәмәгать транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында" 31.01.2014 № 7-1/т Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карарына түбәндәге үзгәртүне кертергә:

Кушымтаны әлеге карарның кушымтасына килештереп яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Түбәндәге карар рәсми рәвештә басылып чыккач 10 көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе    М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 12
сентябрь 2014 ел № 7-18/т
карарына кушымта

## Казан шәһәре җәмәгать транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлары

| Транспорт төре | Бер тапкыр транспортта бару һәм 1 урын багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлары (сум). | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Транспорт салонында билет алган чакта (метрополитен кассасында жетон) | озак вакыт куллану билеты белән түләү | | |
| | | 1 тапкыр бару[1] | 10 тапкыр бару[2] | 50 тапкыр бару[2] |
| Трамвай | 20 | 18 | 18 | 15 |
| Троллейбус | 20 | 18 | 18 | 15 |
| Метро | 20 | 18 | 18 | 15 |
| Автобус | 20 | 18 | 18 | 15 |

<1> Билгеле бер сумма кысаларында, озак вакыт куллану билеты белән шәһәр транспортында бару өчен түләм.;

<2> Билгеле бер вакыт аралагында билгеләнгән тапкыр барырга мөмкинлек биргән, озак вакыт куллану билеты белән шәһәр транспортында бару өчен түләм.

Искәрмә. Багаж өчен транспортта бару бәясенә өстәп түләнелә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештуры һәм җайга салу бүлеге